КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«10» август 2021 ел. № 114-п

Татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» - «Татарский дух и перо» X гомумроссия конкурсын үткәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 25 октябрендәге 794 номерлы карары белән расланган «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклап калу, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында боерык бирәм:

1. Татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» - «Татарский дух и перо» X гомумроссия конкурсын оештырырга һәм үткәрергә.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» - «Татарский дух и перо» X гомумроссия конкурсы турында нигезләмәне;

татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» - «Татарский дух и перо» X гомумроссия конкурсын үткәрү буенча конкурс комиссиясе составын.

3. Әлеге боерык басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары И.Ф. Миргалимовка йөкләргә.

Җитәкче А.С.Сәлимгәрәев

«Татмедиа» республика
матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр
агентлыгының
2021 елның _10 августы_
_114-п_ номерлы боерыгы
белән
РАСЛАНДЫ

Татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен
«Татар рухы һәм каләм» - «Татарский дух и перо» X гомумроссия конкурсы турында
НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 25 октябрендәге 794 номерлы карары белән расланган «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклап калу, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 20 гыйнварындагы 79-р номерлы күрсәтмәсен гамәлгә ашыру кысаларында татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» - «Татарский дух и перо» X гомумроссия конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрү тәртибен, оештыру һәм үткәрү шартларын билгели.

1.2. Конкурсның оештыручылары – «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – Агентлык), Бөтендөнья татар конгрессы регионара иҗтимагый оешмасы (килешү буенча) (алга таба – Оештыручылар).

1.3. Конкурс 2021 елның 6 сентябреннән 2021 елның 30 ноябренә кадәр үткәрелә.

1.4. Конкурсны үткәрү турындагы мәгълүмат Оештыручыларның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://tatmedia.tatarstan.ru, https://tatar-congress.org/ru) «Яңалыклар», «Конкурслар» бүлекләрендә урнаштырыла. Конкурс үткәрү турындагы мәгълүматта номинацияләр,конкурс эшләрен бәяләү критерийлары, Конкурска гаризалар кабул ителә башлау һәм төгәлләнү сроклары, урыны күрсәтелә.

## 2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурсның максатлары:

журналистларның, массакүләм мәгълүмат чараларының (алга таба – ММЧ) милли кыйммәтләрне пропагандалауга, татарлар тормышын һәм эшчәнлеген, шулай ук Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты эшчәнлеген яктыртуга багышланган аеруча әһәмиятле һәм талантлы эшләрен барлау һәм бүләкләү.

2.2. Конкурсның төп бурычлары:

татар халкының тарихи мирасын, традицияләрен һәм гореф-гадәтләрен пропагандалау;

татар халкының милли мәдәниятенә кызыксыну уяту; иҗади багланышларны арттыру һәм ныгыту, журналистларның һөнәри, иҗади үсешен һәм осталыгын арттыру өчен үзара тәҗрибә уртаклашу һәм фикер алмашу;

милләтләр һәм диннәр арасында татулык, килешеп яшәү, толерантлык идеяләрен тарату.

## 3. Конкурска гариза бирүчеләр һәм конкурста катнашучылар

3.1. Конкурста законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән Россия Федерациясе массакүләм мәгълүмат чаралары, аерым авторлар, иҗат коллективлары һәм төркемнәре катнаша.

3.2. Конкурска гариза бирүчеләр – Конкурс турында нигезләмәнең 4.2. пункты нигезендә документлар тапшырган массакүләм мәгълүмат чаралары (законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән) редакцияләре, аерым авторлар, иҗат коллективлары һәм төркемнәре (алга таба – гариза бирүчеләр).

3.3. Конкурста катнашучылар – тапшырылган эшләре Конкурста катнашырга рөхсәт ителгән ММЧ (законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән) редакцияләре, аерым авторлар, иҗат коллективлары һәм төркемнәре (алга таба – катнашучылар).

3.4. Өченче затларның авторлык хокукларын үтәмәгән өчен җаваплылык эшләрне тәкъдим иткән катнашучыларга йөкләнә.

3.5. Гариза бирүчеләр конкурста катнашу өчен әлеге Нигезләмәнең 4 бүлегендә бәян ителгән тәртиптә һәм шартларда документлар әзерләргә һәм тапшырырга тиеш.

3.6. Гариза бирүче Конкурсның бер номинациясендә катнашу өчен бер генә гариза бирә ала.

3.7. Конкурска гариза бирүче берничә номинация буенча документлар тапшыра ала, бу очракта конкурс комиссиясе тарафыннан карала торган документлар һәрбер номинация буенча аерым әзерләнергә тиеш.

## 4. Конкурсны үткәрү шартлары һәм тәртибе

4.1. Конкурска гаризалар 2021 елның 6 сентябреннән кабул ителә башлый.

Конкурска гаризалар кабул итү 2021 елның 31 октябрендә тәгәлләнә.

Конкурс йомгаклары турында мәгълүмат Оештыручыларның рәсми сайтларында 2021 елның 30 ноябрендә урнаштырылачак.

4.2. Конкурста катнашу өчен 2019 елның 1 декабреннән 2021 елның 31 октябренә кадәр Татарстан Республикасы дәүләт телләренең берсендә дөнья күргән конкурс эшләре кабул ителә.

4.3. Агентлык түбәндәге документлар теркәлгән гариза кабул итә:

а) конкурс эшләре (эшләр сериясе (3-10):

MP4 форматындагы DVD дискларда, флешкартада телевизион эшләр (программалар, махсус репортажлар, видеосюжетлар циклы, документаль фильмнар). Конкурс эшләренә эшнең исеме, авторлары һәм эфирга чыгу датасы күрсәтелгән эфир белешмәсе кушып бирелә. Әлеге белешмә редакция мөһере (булган очракта) һәм җитәкче имзасы белән таныкланган булырга тиеш;

MP3 форматындагы DVD дискларда, флешкартада радиоэшләр (программалар, махсус репортажлар, радиосюжетлар циклы). Конкурс эшләренә эшнең исеме, авторлары һәм эфирга чыгу датасы күрсәтелгән эфир белешмәсе кушып бирелә. Әлеге белешмә редакция мөһере (булган очракта) һәм җитәкче имзасы белән таныкланган булырга тиеш;

басма массакүләм мәгълүмат чараларындагы мәкаләләр (язмалар сериясе, махсус чыгарылышлар), төп нөсхә яки күчермә нөсхә рәвешендә/сканер аша чыгарылган вариантта. Язмалар редакция мөһере (булган очракта) һәм җитәкче имзасы таныкланган булырга тиеш;

Интернет басмалардагы язмалар, адреслы сылтама күрсәтелеп, кәгазь вариантта булырга, массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе мөһере белән (булган очракта) һәм җитәкчесе имзасы белән таныкланган булырга тиеш;

CD һәм DVD дискта (флешкартада) видеороликлар;

CD һәм DVD дискта (флешкартада) фотоматериаллар;

б) катнашу өчен анкета (1 нче кушымтадагы форма буенча);

в) юридик зат буларак теркәлгән массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен:

юридик затны салым органында исәпкә кую турында таныклык (ИНН) (күчермәсе);

юридик зат җитәкчесен вазыйфага билгеләп кую турында боерык (күчермәсе);

гамәлгә кую документлары (күчермәләре);

ММЧ теркәү турында таныклык (күчермәсе) яисә теркәлгән массакүләм мәгълүмат чаралары реестрыннан күчермә;

г) юридик зат булмаган массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен:

массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык (күчермәсе);

массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе уставы яисә, массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясендә кимендә 10 кеше эшләсә, “Массакүләм мәгълүмат чаралары турында” 1991 елның 27 декабрендәге 2124-I номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба – ММЧ турында Закон) 20 статьясы нигезендә аны алмаштыра торган шартнамә;

д) уртак эшләр тәкъдим итә торган авторлар, иҗат коллективлары өчен:

шәхесне таныклаучы документ (күчермәсе);

әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә Персональ белешмәләрне эшкәртүгә, тапшыруга ризалык бирү;

персональ белешмәләр субъекты рөхсәт иткән персональ белешмәләрне таратуга ризалык (3 нче кушымта нигезендә);

Уртак эшләр биргән автор коллективлары яки ММЧ редакцияләре, конкурс эше призлы урын бирелгән очракта, акчаларны процент нисбәтендә бүлү турындагы килешүне өстәмә рәвештә тәкъдим итә.

е) уртак эшләр тапшыра торган массакүләм мәгълүмат чаралары, иҗат коллективлары өчен – конкурс эшенә призлы урын бирелгән очракта, акчаны процентлап бүлешү турында килешү.

Әлеге пунктның «б» – «е» пунктчаларында күрсәтелгән документлар кәгазь вариантта (оешма җитәкчесенең имзасы белән тамгалана һәм оешма мөһере (булган очракта) сугыла) яисә сканердан чыгарып, PDF форматында электрон документ рәвешендә җибәрелә.

4.4. Конкурска килгән эшләргә рецензия бирелми.

4.5. Гаризалар түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 420097, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт, «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы, 6 кат, 608 нче кабинет. Телефон: 8 (843) 570-31-12

4.6. Документларның Агентлыкка килгән көне аларны тапшыру датасы дип санала.

4.7. Конкурста катнашуга рөхсәт бирмәү өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

гаризаны билгеләнгән срокны бозып тапшыру;

әлеге Нигезләмәнең 4.2., 4.3. пунктларында каралган документларны гаризага теркәмәү;

анкета-гаризаның/конкурс эшенең әлеге Нигезләмәгә туры килмәве

сурәтендә яисә тавышында хилафлыклар булган эшләрне тәкъдим итү

искерүгә яки югалтуга китерә торган дефектлары булган электрон чыганакта заявкалар бирү.

4.8. Катнашучыга Конкурска кертелмәү турында хәбәр документларны алган мизгелдән алып 3 эш көне дәвамында Оештыручы җитәкчесе/җитәкче урынбасары (аның вазыйфаларын башкаручы зат) имзалаган һәм анкета-гаризада күрсәтелгән адреска җибәрелгән заказлы рәсми хат белән хәбәр ителә.

4.9. Конкурска йомгак конкурс комиссиясе тарафыннан 2021 елның 30 ноябреннән дә соңга калмыйча ясала.

Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү турында Оештыручыларның рәсми сайтларында өстәмә рәвештә хәбәр ителә.

4.10. Конкурсны оештыручылар эшләрне, шул исәптән бүләкләргә лаек булган эшләрне дә киләчәктә файдалануны күздә тотмый, шуңа бәйле рәвештә конкурста катнашучылар эшләрне киләчәктә ничек файдалануны мөстәкыйль хәл итә. Бу авторга иҗади эштән үзе теләгәнчә файдаланырга, аерым алганда, килешү төзерлек зат яисә оешма табу мөмкинлеген бирә.

4.11. Конкурс шартлары буенча, тәкъдим ителгән эшләрне катнашучыларга/гариза бирүчеләргә кире кайтару, конкурста катнашучының/гариза бирүченең эшне кире кайтару турындагы таләбе буенча гына, мондый таләп алынган мизгелдән алып 20 (егерме) календарь көн дәвамында алар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

4.12. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (почта, командировка һ.б.) Гариза бирүче/Катнашучы тарафыннан мөстәкыйль түләнә.

## 5. Конкурсның номинацияләре

5.1. Конкурс түбәндәге номинацияләрдә үткәрелә:

«Массакүләм мәгълүмат чараларында татар халкының тормышына һәм эшчәнлегенә багышланган иң яхшы эшләр циклы»;

«ТАССР төзелүнең 100 еллыгына багышланган иң яхшы эшләр циклы»;

«Теле барның – иле бар». 2021 елгы Бөтенроссия халык саны алуга багышланган иң яхшы материал (махсус номинация).

## 6. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары

6.1. Конкурс эшләрен бәяләгәндә түбәндәге критерийлар кулланыла:

- конкурс эшләренең  Конкурс максатларына һәм бурычларына туры килүе (0-5 балл);
- тапшырылган эшләрнең актуаль, объектив һәм тикшерелгән, аналитик яктан тирән булуы (0-5 балл);
- тәрбияви һәм иҗтимагый кыйммәте,  авторның гражданлык позициясе чагылу (0-5 балл);
- эшнең югары һөнәри дәрәҗәдә эшләнүе (адресат тарафыннан җиңел кабул ителү, тел-сурәтләү чаралары куллану, композиция-структура төзелешенең югары сыйфатлы дизайны һәм бизәлеше) (0-5 балл);
- тапшырылган эшләрнең матур әдәби телдә булуы (0-5 балл);
- концепциянең, сценарийның, теманың, теманы яктыртуның  кабатланмаган булуы,шәхси иҗат стиле булу (0-5 балл).

## 7. Конкурс комиссиясен оештыру һәм аның эшчәнлек тәртибе

7.1. Конкурс комиссиясенең составы Конкурсны оештыручы тарафыннан раслана, 7 әгъзадан тора, аларга рәис, рәис урынбасары һәм әгъзалар керә.

7.2. Конкурс комиссиясе үз эшен түләүсез башкара.

7.3. Конкурс комиссиясенең эше утырышларда гамәлгә ашырыла. Утырышта комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, утырыш тулы хокуклы дип таныла.

7.4. Конкурс эшенә рәис җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда, рәис вазыйфалары аның тарафыннан билгеләнгән урынбасарына йөкләнә.

7.5. Конкурс комиссиясе әгъзалары конкурска тапшырылган эшләрне әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән Конкурс эшләрен бәяләү критерийлар нигезендә бәяли.

Һәрбер гариза буенча баллар саны, конкурс комиссиясе әгъзалары куйган бәядән чыгып, уртача баллны исәпләү юлы белән чыгарыла.

7.6. Бер номинациягә бер генә гариза тапшырылса, бер гариза да тапшырылмаса, тапшырылган гаризаларның берсе дә конкурс шартларына туры килмәсә, катнашкан эшләрнең берсе дә билгеләп үтәргә лаек дип танылмаса, Конкурс бу номинациядә үткәрелмәгән дип таныла һәм акчалар билгеләнгән башка җиңүчеләр арасында тигез итеп бүленә.

7.7. Һәр критерий буенча баллар суммасы буенча конкурс комиссиясе конкурста катнашучылар рейтингын төзи. Җиңүчеләр җыелган баллардан чыгып билгеләнә. Баллар тигез булганда Конкурс комиссиясе әгъзалары карары нигезендә призлы урыннар ике яисә берничә җиңүчегә бирелергә мөмкин, бу очракта әлеге призлы урынга тәгаенләнгән акчалар җиңүчеләр арасында тигез өлешләп бүленә.

7.8 Номинациядә премия бирелгән конкурс эшендә берничә автор, иҗади коллективлар, массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре күрсәтелгән очракта, премиягә бүлеп бирелгән акчалар, конкурс комиссиясенә тапшырылган килешү нигезендә, күрсәтелгән затлар арасында Агентлык тарафыннан бүленә.

7.9. Конкурсны оештыручы оештыру-техник эшчәнлекне җайга салу, утырышны әзерләү һәм конкурс комиссиясе документациясен алып бару өчен җаваплы секретарь билгеләп куя.

7.10. Җаваплы секретарь конкурс комиссиясе составына керми һәм утырышларда тавыш бирү хокукыннан башка гына катнаша.

7.11. Конкурс комиссиясе утырышы уздырылган көннән алып биш эш көне эчендә Конкурс комиссиясе утырышы йомгаклары буенча беркетмә рәсмиләштерелә, аңа утырышта булган конкурс комиссиясе әгъзаларының имзасы салына, беркетмә конкурс комиссиясе рәисе яисә рәисе урынбасары тарафыннан раслана.

7.12. Конкурс йомгаклары календарь көннәрдә исәпләнә торган өч көн эчендә беркетмәгә имза салынган көннән Оештыручыларның рәсми сайтларында урнаштырыла.

## 8. Финанслау

8.1. Конкурсны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 25 октябрендәге 794 номерлы карары белән расланган “2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклап калу, өйрәнү һәм үстерү” дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында каралган акчалар исәбеннән тотыла.

8.2. Гомуми приз фонды – 162,0 мең сум.

8.3. Конкурста җиңүчеләр чәчәкләр, дипломнар һәм акчалата премияләр белән түбәндәге тәртиптә бүләкләнә:

| № | Номинацияләр | Премияләр саны | Премия суммасы (мең сум) | Гомуми сумма (мең сум) |
|---|---|---|---|---|
| 1. | «Массакүләм мәгълүмат чараларында татар халкының тормышына һәм эшчәнлегенә багышланган иң яхшы эшләр циклы»; | 3 | 18,0 | 54,0 |
| 2. | «ТАССР төзелүнең 100 еллыгына багышланган иң яхшы эшләр циклы» | 3 | 18,0 | 54,0 |
| 3. | «Теле барның – иле бар». 2021 елгы Бөтенроссия халык саны алуга багышланган иң язшы материал (махсус номинация) | 3 | 18,0 | 54,0 |
| Барлыгы | | | | 162,0 |

8.4. Юридик затларга акчалата премияләр Конкурс йомгаклары турында беркетмәгә имза салган мизгелдән алып 20 көн дәвамында, җиңүчеләрне игълан иткәннән соң, Агентлык җитәкчелегенә язылган рәсми хатта күрсәтелгән исәп-хисап счетына күчерү юлы белән түләнә.

8.5. Физик затларга акчалата премияләр Конкурс йомгаклары турында беркетмәгә имза салган мизгелдән алып 20 көн дәвамында, җиңүчеләрне игълан иткәннән соң, Агентлык җитәкчелегенә язылган рәсми хатта күрсәтелгән исәп-хисап счетына күчерү юлы белән түләнә.

## 9. Аерым шартлар

9.1.Оештыручылар түбәндәгеләргә хокуклы:

- әлеге Нигезләмәдә һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән очраклардан, шулай ук бәхәсле очраклардан тыш, Конкурста катнашучылар белән язмача йә башка төрле элемтәләргә кермәскә;
- эшләрне тапшыру срогының беренче яртысында Россия Федерациясе законнары таләпләрен (РФ ГК 1058 ст.) үтәп, Конкурсны туктатырга яки әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә, бу хакта Оештыручыларның рәсми сайтында тиешле мәгълүмат урнаштырып, Катнашучыларга хәбәр итәргә.

9.2. Конкурс шартлары үзгәрү турында хәбәрнамә алганнан соң, Конкурста катнашучы эшләрне элек билгеләнгән шартларда кабул итүне яисә кертелгән үзгәрешләрне гамәлдә түгел дип тануны таләп итә алмый. Аның эшне Конкурсның яңа шартларына туры китереп үзгәртүе алга таба конкурста катнашырга мөмкинлек бирә.

Татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» - «Татарский дух и перо» Х гомумроссия конкурсы турында нигезләмәгә

1 нче кушымта

Татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» - «Татарский дух и перо» Х гомумроссия конкурсында катнашу өчен гариза

**Гариза бирүче (**автор, иҗат коллективы, ММЧ редакциясе)

______________________________________________________________

**Җитәкче**

______________________________________________________________

**Телефон**

______________________________________________________________

**Материалның чыгу датасы**

______________________________________________________________

**Номинация**

______________________________________________________________

**Конкурс эшенең исеме**

______________________________________________________________

**Кыскача эчтәлеге**

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

____________________________________________________________

**Адрес**

______________________________________________________________

**Телефон/факс**

________________________________________________________________

**e-mail**

________________________________________________________________

Эшләрне конкурска тәкъдим итү өченче затларның авторлык хокукын яисә башка хокукларын бозмый.

**Массакүләм мәгълүмат чарасы җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме**
**(тулысынча)**____________________________________________________

(җитәкче имзасы, мөһер (булган очракта)

Татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» - «Татарский дух и перо» X гомумроссия конкурсы турында нигезләмәгә

2 нче кушымта

(тәкъдим ителә торган форма)

**Персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

Мин,______________________________________________________________________________,
яшәү адресым______________________________________________
______________________________________________________________________________,
шәхесне таныклаучы төп документым (паспорт)______________________
______________________________________________________________________________
__________________________________, «Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (алга таба – оператор) (адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» - «Татарский дух и перо» X гомумроссия конкурсында катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне эшкәртүгә, аларны җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), алардан файдалануны, аларны таратуны (шул исәптән башкаларга тапшыруны), үз исемемнән башка файдалануны, блокировать итүне, юкка чыгаруны да кертеп, ризалыгымны бирәм.
Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге:

| | |
|---|---|
| Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге: | (фамилия, исем, атасы исеме, җенес, туган көн һәм урын, гражданлык, шәхесне таныклаучы документның реквизитлары (документ төре, сериясе һәм номеры, кем тарафыннан бирелүе), яшәү урыны, теркәлү урыны, телефон номеры (шул исәптән кәрәзле телефон), электрон почта адресы, Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счеты турында белешмәләр) |

Әлеге ризалык имзаланган көннән алып 1 (бер) ел гамәлдә була.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны, бу хакта операторга язмача хәбәр итеп, кире алырга хокуклы.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны кире алган очракта оператор аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм, персональ белешмәләрне эшкәртү өчен аларны саклау башкача кирәк булмаса, ризалыкны кире алу турында мөрәҗәгать кергән көннән алып утыз көн эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) тиеш. Күрсәтелгән вакыт эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор аларны блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм персональ белешмәләрне иң күп дигәндә алты ай эчендә юкка чыгара.

______________________________________________________________________/________________

(персональ белешмәләр субъектының Ф.И.Ат ис. (булган очракта күрсәтелә) һәм имзасы)

________________

(Дата)

Татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» - «Татарский дух и перо» X гомумроссия конкурсы турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

(тәкъдим ителә торган форма)

**Тарату өчен персональ белешмәләр субъекты тарафыннан рөхсәт ителгән персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

Мин, __________________________________________________________________,
(фамилия, исем, атасының исеме (булган очракта) рус телендә)

______________________________________________________________________,
(почта адресы)

______________________________________________________________________,
(электрон почта адресы)

______________________________________________________________________,
(телефон номеры)

«Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның $10^1$ статьясы нигезендә “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (ОГРН 1031621014765, ОКТМО 92701000, ОКПО 14912163) юридик адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» - «Татарский дух и перо» X гомумроссия конкурсында катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне таратуга (шул исәптән башкаларга тапшыруга, бирүгә) ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалык бирелә торган персональ белешмәләрнең категориясе һәм исемлеге

| N т/с | Персональ белешмәләр | Ризалык | |
|---|---|---|---|
| | | Әйе | ЮК |
| Гомуми персональ белешмәләр | | | |
| | Фамилия | | |
| | Исем | | |
| | Атасы исеме (булган очракта) | | |
| | Туган ел, ай, дата һәм урын | | |
| | Адрес | | |
| | Белем | | |
| | Һөнәр | | |

Эшкәртү өчен шартлар һәм тыю билгеләнә торган персональ белешмәләрнең категориясе һәм исемлеге

| N т/с | Персональ белешмәләр | Билгеләнә торган шартлар һәм тыюлар исемлеге |
|---|---|---|
| **1. [Персональ белешмәләрнең категориясе]** | | |
| | **[Персональ белешмәләрнең исемлеге]** | |

Искәрмә. Күрсәтелгән таблица персональ белешмәләр субъектының теләге буенча, персональ белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыра торган оператор тарафыннан чикләүләрсез тутырыла.
Шартлар һәм тыюлар операторның чикләнмәгән яисә кайбер даирә затларына әлеге персональ белешмәләрне таратуга һәм (яисә) тапшыруга бәйле гамәлләрен чикләүне йә тыюны күздә тота.
Ризалыкта өстәмә шартлар да күрсәтелергә мөмкин, алар алынган персональ белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыра торган оператор тарафыннан мәгълүмат кайбер хезмәткәрләргә генә җиткерелә торган эчке элемтәләр буенча йә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша тапшыруны, яки алынган персональ белешмәләрне тапшырмауны күздә тота

Операторның персональ белешмәләр субъектының персональ белешмәләре чикләнмәгән яисә кайбер даирә затларына тапшырылырга мөмкин мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр: http://tatmedia.tatarstan.ru/.

Әлеге ризалык ______________________________ срокта гамәлдә була.
**(ризалыкның гамәлдә булу срогы)**

Персональ белешмәләр субъекты, операторга язмача хәбәр итеп, үзенең персональ белешмәләрен эшкәртүгә бирелгән ризалыктан баш тартырга хокуклы.
Персональ белешмәләр субъекты, операторга язмача хәбәр итеп, үзенең персональ белешмәләрен эшкәртүгә бирелгән ризалыктан баш тарткан очракта оператор мондый баш тартуны алган көннән алып иң күбе утыз көн эчендә аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) һәм, элек куелган максатлар өчен персональ белешмәләрне эшкәртү башкача таләп ителмәсә, персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) тиеш.
Күрсәтелгән срокта персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор мондый персональ белешмәләрне блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) һәм персональ белешмәләрне алты айдан артмаган срокта юкка чыгаруны тәэмин итә.

_____________( персональ белешмәләр субъекты имзасы)
_____________ (число, ай, ел)